**КАРАР № 3**

Күки авылы 14 апрель 2017 ел

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре проекты турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 28 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15, 20 статьялары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Күки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 5,19,33 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Күки авыл җирлеге үзидарә органына тапшырырга карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Күки авыл җирлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләре проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм аны халык алдында тыңлауларга чыгарырга.

2. Расларга:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Күки авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе №2 кушымта нигезендә;

3 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Күки авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе.

3. Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге территориясен төзекләндерү (алга таба-оештыру комитеты) проекты буенча керүче тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта оештыру комитетын төзергә:

Хөснетдинова Р.Ә. – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге башлыгы, оештыру комитеты рәисе;

Мөхәммәтшина Г.Х. – 2 нче сайлау округы депутаты, оештыру комитеты әгъзасы;

Гәлиәскәров С.Г.– 4 нче сайлау округы депутаты, оештыру комитеты әгъзасы;

4. Балык Бистәсе муниципаль районының Күки авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлауларны 2017 елның 30 апреленә 11.00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча билгеләргә: ТР, Балык Бистәсе муниципаль районы, Күки авылы, Г .Тукай урамы, 28а йорт.

5. Оештыру комитетына, гавами тыңлауларда белдерелгән тәкъдимнәрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Күки

авыл җирлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләре проектын эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Күки авыл җирлеге Советына икенче укылышта кабул итү өчен кагыйдәләр проектын Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Күки авыл җирлеге Советына кертүне тәэмин итәргә.

6. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Күки авылы, Яңа урамы, 5 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

7. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күки авыл җирлеге башлыгы А.М.Бәдретдинов